# Карун

قرون

اللغة التتارية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд
Сәрхән

ALSARHAAN.COM
Mahadsunnah.com

قال تعالى
إِنَّ قَٰرُونَ كَانَ مِن قَوۡمِ مُوسَىٰ فَبَغَىٰ عَلَيۡهِمۡۖ وَءَاتَيۡنَٰهُ مِنَ ٱلۡكُنُوزِ مَآ إِنَّ مَفَاتِحَهُۥ لَتَنُوٓأُ بِٱلۡعُصۡبَةِ أُوْلِي ٱلۡقُوَّةِ
(القصص: ٧٦)

Аллаһ әйтте: «Хакыйкатькә, Карун Муса кавеменнән иде һәм ул аларны рәнҗетте. Без аны шундый байлык белән нигъмәтләндердек, хәтта аның хәзинә сарайларының ачкычларын куәт ияләренә дә күтәрергә авыр иде».
(Касас сүрәсе, 76 аять)

فقد آتاه الله تعالى اموالًا طائلة. وكنوزا ضخمة بلغ من ضخامتها أن الأقوياء من الرجال كان يثقلهم حمل مفاتيحها.

Аллаһ аңа зур байлык бирде, һәм ул хәзинәләрнең күләме шулкадәр күп иде, хәтта ир-атларның иң көчлеләренә дә шул байлык саклана торган җирнең ачкычларын ташу бик авыр иде.

ولكن عدو الله بغى وتجبر. .

Ләкин Аллаһның дошманы золымлык кылып, үз-үзен барысыннан да өстен күреп, тәкәбберләнде.

وخرج عن طاعة موسى عليه السلام.

Һәм Мусага, Аллаһның аңа сәламе булсын, буйсынмады.

فقال له بعض قرابته ناصحين له محذرين.

Һәм аның якындашларыннан кайберәүләре аңа үгет-нәсыйхәт ясап аны кисәттеләр:

لَا تَفۡرَحۡۖ إِنَّ ٱللَّهَ لَا يُحِبُّ ٱلۡفَرِحِينَ (القصص: ٧٦)

Малың күплеге белән куанма, хакыйкатьтә, Аллаһ мактанып куанучыларны яратмый. (Касас сүрәсе, 76 аять)

وَٱبۡتَغِ فِيمَآ ءَاتَىٰكَ ٱللَّهُ ٱلدَّارَ ٱلۡأٓخِرَةَۖ (القصص: ٧٧)

Аллаһ сиңа биргән нигъмәтләр сәбәпле ахирәткә омтыл. (Касас сүрәсе, 77 аять)

أي لا تفرح بلذات الدنيا. معرضا عن الدين والعمل للآخرة.

Диннән, ахирәттә файда китерә торган изге гамәлләрдән ваз кичеп, бу дөнья ләззәтләренә куанма.

فقال قارون رادا لنصيحتهم:
[إِنَّمَآ أُوتِيتُهُۥ عَلَىٰ عِلۡمٍ عِندِيٓۚ] (القصص ٧٨)

Һәм Карун аларның үгет-нәсыйхәтләренә каршы килеп: "Миңа бит бу байлыклар үземдә булган гыйлем аркасында бирелде",- дип әйтте.

ولم يزل قارون مستمرا على عناده وبغيه.

Карун үз тискәрелегендә һәм золымлыгында калды.

وعدم قبول نصيحة قومه
فرحا بطرا قد أعجبته نفسه.

Һәм үз халкының үгет-нәсыйхәтен артык куану һәм тәкәбберлеге сәбәпле кабул итмәде һәм үз-үзе белән сокланды.

وغره ما أوتيه من الأموال.

Аңа бирелгән мал аны ымсындырды.

فخرج ذات يوم على قومه في هيئة عظيمة وتجمل باهر من مراكب وملابس عليه وعلى خدمه وحشمه.

Бер көнне ул үз халкы каршына бизәнеп күренелекле кыяфәттә чыкты, аның атын һәм киемнәрен, шулай ук яраннарының һәм хезмәтчеләренең киемнәрен җем-җем итә торган ялтыравыклар бизәгән иде.

فلما رآه من يريد الحياة الدنيا ويميل الى زخرفها وزينتها. تمنوا أن لو كان لهم مثل ما أعطي. فقالوا [يَٰلَيۡتَ لَنَا مِثۡلَ مَآ أُوتِيَ قَٰرُونُ إِنَّهُۥ لَذُو حَظٍّ عَظِيمٍ ] (القصص ٧٩)

Бу дөньяны яратучылар һәм аның бизәкләренә, байлыкка кызыгучылар аны күргәч, аларда да шундый ук нәрсәләр булуын теләделәр : «Эх, бездә дә Карунга бирелгән байлык булса иде, чынлыкта, ул муллык иясе»,- дип әйттеләр.

فلما سمع مقالتهم أهل العلم النافع قالوا لهم ويلكم ثواب الله خير لمن آمن وعمل صالحا.

Гыйлем ияләре бу сүзләрне ишеткәч: "Кайгы сезгә, Аллаһка ышанып изге гамәлләр кылучыларга бирелгән әҗер-савап хәерлерәк",- дип әйттеләр.

ولا يلقاها إلا الصابر

Һәм бу әҗер-савап сабыр булганнарга гына биреләчәк.

ولما انتهت بقارون حالة البغي والفخر وازينت الدنيا عنده وكثر بها اعجابه بغته العذاب فخسف الله به وبداره الأرض.

**Карунның золымлык кылуы, тәкәбберләнүе, дөнья нигъмәтләренә гәҗәпләнүе чиккә җиткәч, Аллаһ аңа кинәт газаб җибәреп, аны һәм йортын җиргә йоттырды.**

جزاء من جنس عمله.

**Һәм бу җәза аның гамәлләренә карата бирелде.**

فكما رفع نفسه أنزله الله تعالى أسفل سافلين هو وما اغتر به من داره وأثاثه ومتاعه فما نُصِرَ ولا انتصر

**Ул үз-үзен ничек бөекләгән булса, Аллаһ Карунны һәм ул алданган өен, җиһазларын һәм рәхәтлекләрен дә иң түбән булган җиргә шулай төшерде ки, хәтта ул коткарылмады да һәм үз-үзен дә саклый алмады.**

وَأَصۡبَحَ ٱلَّذِينَ تَمَنَّوۡاْ مَكَانَهُۥ بِٱلۡأَمۡسِ يَقُولُونَ وَيۡكَأَنَّ ٱللَّهَ يَبۡسُطُ ٱلرِّزۡقَ لِمَن يَشَآءُ مِنۡ عِبَادِهِۦ وَيَقۡدِرُۖ لَوۡلَآ أَن مَّنَّ ٱللَّهُ عَلَيۡنَا لَخَسَفَ بِنَاۖ وَيۡكَأَنَّهُۥ لَا يُفۡلِحُ ٱلۡكَٰفِرُونَ
(القصص ٨٢)

**Әле күптән түгел генә Карунның дәрәҗәсен өмет итүче кешеләр Карунның йорты белән җир астына киткәнен күреп: “Бәлки, Аллаһ сынар өчен теләгән бәндәсенә ризыгын киңәйтәдер һәм теләгән бәндәсенә киметәдер, әгәр Аллаһ без теләгәнчә безгә дә Карун малы кебек мал биргән булса. Әлбәттә, без дә Карун белән бергә җир астына киткән булыр идек, көферлек кылучылар уңышка ирешмәсләр”, – дип әйттеләр.**